СОВЕТ ВЕРХНЕСУБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
«11» ноябрь 2025 г.

**КАРАР**
№ 9

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге Советы регламентына өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы карар кабул итте:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Советының 20.12.2010 №17 карары белән расланган Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Советы регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.Регламентның 35 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Карар кабул иткәндә хәлиткеч тавыш хокукына ия депутатларның "хуплыйм" һәм "каршы" бирелгән тавышлары саны тигез булган очракта, Совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.».

2. Әлеге карар имзаланган вакыттан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә baltasi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны тәэкләндерү, тәзелеш, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы А.А. Хөснетдинов